**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында**

Татарстан Республикасы Конституциясенең 94 статьясы 2 өлеше нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты атамасын Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе дип үзгәртергә.

2. Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә структур бүлекчәләр һәм вазыйфалар атамаларында Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты вазыйфасы атамасы буларак Татарстан Республикасы Рәисе атамасы кулланыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең, Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе Җитәкчесенең «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы үз көченә кергән көнгә кадәр кабул ителгән хокукый актларында «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты», «Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе» атамалары, шул исәптән вазыйфалар атамаларында булганнары да, аларга тиешле үзгәрешләр кертелгәнгә кадәр, «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе» атамасына тәңгәл санала дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе составына Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенең беренче урынбасары һәм урынбасарлары, Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәчесе һәм аның урынбасары, Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы Секретаре, Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы вәкаләтле вәкиле, Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчеләре, башка вазыйфаи затлар, шулай ук түбәндәге структур бүлекчәләр керә дип билгеләргә:

Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе секретариаты;

Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты, аның составына түбәндәгеләр керә: Гражданлык җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек идарәсе, Дини берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек идарәсе, Милли сәясәтне гамәлгә ашыру идарәсе, иҗтимагый проектлар бүлеге;

Татарстан Республикасы Рәисенең Территорияләр белән эшләү идарәсе;

Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт-хокук идарәсе;

Татарстан Республикасы Рәисенең Тышкы элемтәләр департаменты;

Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт протоколы идарәсе;

Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе;

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты;

Татарстан Республикасы Рәисенең Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү идарәсе;

Татарстан Республикасы Рәисенең Документлар белән тәэмин итү һәм контроль идарәсе;

Татарстан Республикасы Рәисенең Матбугат хезмәте;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең дәүләт бүләкләре бүлеге;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең махсус документаль элемтә бүлеге;

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарларның хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге;

Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе, аның составына түбәндәгеләр керә: бухгалтерлык исәбе һәм хисабы бүлеге, мәгълүмати-техник тәэминат бүлеге, чараларга хезмәт күрсәтү һәм биналарны карап тоту бүлеге, гомуми бүлек;

Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге;

Татарстан Республикасы Рәисенең Эксперт департаменты, аның составына түбәндәгеләр керә: Икътисадый анализ идарәсе, җир-мөлкәт мөнәсәбәтләрен координацияләү һәм үстерү бүлеге, Татарстан Республикасы Рәисенең рәсми чыгышларын әзерләү бүлеге;

Татарстан Республикасы Рәисенең Мәгълүмат-аналитика идарәсе.

5. Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

6. Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе структурасын һәм хезмәткәрләренең чик санын расларга (2 нче кушымта – хезмәт урынында файдалану өчен).

7. Татарстан Республикасы Президенты указларына 3 нче кушымтадагы исемлек нигезендә үзгәрешләр кертергә.

8. Татарстан Республикасы Президентының аерым актларын 4 нче кушымтадагы исемлек нигезендә үз көчен югалткан дип танырга.

9. Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә 60 көн эчендә Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе эшчәнлеген җайга сала торган Татарстан Республикасы хокукый актларын үзгәртү буенча тәкъдимнәр бирергә.

10. Әлеге Указ 2023 елның 6 февраленнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 04 февраль
№ ПУ-68

Татарстан Республикасы
Президентының
2023 елның «04»февралендәге
ПУ-68 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында нигезләмә**

**I. Гомуми нигезләмәләр**

1. Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе (алга таба – Администрация) Татарстан Республикасы Рәисе, шулай ук билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы консультатив, киңәшмә һәм башка органнар эшчәнлеген оештыру ягыннан, хокукый, аналитик, документлар белән, мәгълүмати, матди-техник һәм башкача тәэмин итүне тормышка ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт органы булып тора.

2. Администрация Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан төзелә һәм үзенең эшчәнлеген Татарстан Республикасы Рәисе җитәкчелегендә тормышка ашыра.

Администрациягә Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе җитәкчелек итә.

3. Администрация үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Рәисе указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларына, Администрация регламентына һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

4. Администрация турында нигезләмә, Администрация регламенты Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

5. Администрация үзенә йөкләнгән функцияләрне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, федераль дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләре һәм массакүләм мәгълүмат чаралары, башка оешмалар һәм гражданнар белән үзара хезмәттәшлек итә.

## II. Администрациянең төп бурычлары һәм функцияләре

6. Администрациянең төп бурычы – Татарстан Республикасы Рәисенең дәүләт башлыгы, Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты функцияләрен, Татарстан Республикасы Рәисенә Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә йөкләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыруын тәэмин итү.

7. Төп бурычларын тормышка ашыру максатларында Администрация түбәндәге функцияләрне башкара:

Татарстан Республикасы Рәисе йөкләве буенча Татарстан Республикасы Рәисе указлары, боерыклары проектларын әзерли, аларның рәсми төстә басылып чыгуын тәэмин итә;

Татарстан Республикасы Рәисе йөкләве буенча Татарстан Республикасы Рәисенең закон чыгару инициативасы тәртибендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү өчен закон проектларын әзерләүне оештыра, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Рәисенең еллык юлламалары өчен материаллар, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелә торган закон проектларына бәяләмәләр проектларын әзерли;

Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы законнарына кул кую яисә аларны кире кагу турында тәкъдимнәр әзерли, Татарстан Республикасы Рәисе кул куйган законнарны халыкка җиткерүне тәэмин итә;

республикада һәм аерым муниципаль берәмлекләрдә социаль-икътисадый, иҗтимагый-сәяси вазгыять турында мәгълүмат җыюны, эшкәртүне һәм анализлауны оештыра, аналитик докладлар, мәгълүматлар, белешмәләр, эчке сәясәт һәм тышкы эшчәнлекнең иң мөһим мәсьәләләре буенча, республикада, аерым муниципаль берәмлекләрдә вазгыять үсеше мөмкинлекләре турында Татарстан Республикасы Рәисенә кирәк булган башка материалларны һәм документларны әзерли;

Татарстан Республикасы Рәисе указлары, боерыклары һәм йөкләмәләре үтәлешен контрольдә тотуны башкара;

Татарстан Республикасы Рәисе очрашуларын, чараларын, эш сәфәрләрен, сөйләшүләрен, ул катнаша торган киңәшмәләрне планлаштыра, координацияли, әзерли һәм уздыруны тәэмин итә, кирәк булганда, аларны оештыру-техник яктан тәэмин итүне башкара;

Татарстан Республикасы Рәисенең сәяси партияләр, җәмәгать һәм дини берләшмәләр, һөнәр берлекләре, граждан җәмгыятенең башка структуралары белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә;

дәүләт граждан хезмәте турында законнар нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә идарә итү өлкәсендә карарлар кабул итүне гамәлгә ашыра, әлеге өлкәдә тиешле хокукый актлар белән билгеләнгән башка функцияләрне үти;

Татарстан Республикасы Рәисенә вазыйфага билгеләп кую (тәкъдим итү, килештерү, раслау) һәм вазыйфадан азат итү өчен аерым кандидатуралар, классны чиннар бирү буенча тәкъдимнәр кертә, Татарстан Республикасы Рәисенә кадрлар мәсьәләсе буенча вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда башкача ярдәм күрсәтә;

Татарстан Республикасының тышкы элемтәләрен тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы Рәисе эшчәнлеген тәэмин итә, Татарстан Республикасы шартнамәләре һәм килешүләре проектларын әзерли;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән бергә Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы бюджеты турында, Татарстан Республиканың озак вакытка каралган социаль-икътисадый үсеше стратегиясе турында закон проектларын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында еллык хисапларны, шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы куйган мәсьәләләр буенча да, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт программаларын тормышка ашыру барышы һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү турында еллык җыелма хисапларны тапшыруны тәэмин итә;

федераль законнар нигезендә федераль законнар проектларына бәяләмәләр әзерли;

Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы Рәисенә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының федераль башкарма хакимият органнары һәм аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлеге буенча тәкъдимнәр әзерли;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары уздыра торган, шул исәптән федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары катнашында уздырыла торган республика чараларын координацияләүне башкара;

законнар нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә сайлау процессларына булышлык итә;

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы консультатив һәм киңәшмә органнары эшчәнлеген оештыру-техник һәм мәгълүмати яктан тәэмин итүне тормышка ашыра;

Татарстан Республикасы Рәисе йөкләве буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары проектларына бәяләмәләр әзерли, законнарда каралган очракларда Татарстан Республикасы Рәисенә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларының гамәлен туктату турында тәкъдимнәр әзерли;

Россия Федерациясе Конституция Судында, гомуми юрисдикция судларында, арбитраж судларында Татарстан Республикасы Рәисе мәнфәгатьләрендә вәкиллек итүне тәэмин итә;

дәүләт граждан хезмәткәрләренә салынган тыюларны, чикләүләрне үтәү өлешендә, коррупциягә каршы эшчәнлекне оештыру буенча

законнарны үтәүгә контрольне тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы Рәисе эшчәнлеген тәэмин итә;

Татарстан Республикасы Рәисенең гражданнарны кабул итүен, Татарстан Республикасы Рәисе адресына килә торган гражданнар, җәмәгать берләшмәләре мөрәҗәгатьләрен исәпкә алуны, карауны, анализлауны, гомумиләштерүне оештыра;

Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү, республика премияләрен, стипендияләр, грантлар, бүләкләүнең башка төрләрен бирү буенча эшне оештыра;

массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлекне, Татарстан Республикасы Рәисенең, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы аерым органнарның эшчәнлеген массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итә, Татарстан Республикасы Рәисенең мөрәҗәгатьләрен, белдерүләрен, әңгәмәләрен, чыгышларын бастыруны тормышка ашыра;

Татарстан Республикасы Рәисе йөкләве буенча башка вәкаләтләрне тормышка ашыра.

## III. Администрациянең структурасы һәм аның эшен оештыру

8. Администрация структурасына Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенең беренче урынбасары һәм урынбасарлары, Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәчесе һәм аның урынбасары, Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы Секретаре, Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы вәкаләтле вәкиле, Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчеләре, башка вазыйфаи затлар, шулай ук түбәндәге структур бүлекчәләр: департаментлар, идарәләр, бүлекләр, матбугат хезмәте, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе секретариаты, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты керә.

Департаментлар, идарәләр, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты составында бүлекләр, секторлар, бүлекләр составында секторлар төзелергә мөмкин. Татарстан Республикасы Рәисе карары буенча Татарстан Республикасы Рәисе Департаменты составында Департаментның структур бүлекчәләре булып торган идарәләр, бүлекләр, секторлар төзелергә мөмкин. Департамент идарәсендә бүлекләр, секторлар төзелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе каршында, кирәк булганда, башка бүлекчәләр, шулай ук аңа буйсынган, шул исәптән юридик зат хокуклары бирелгән оешмалар төзелергә мөмкин.

9. Администрациянең структурасы һәм хезмәткәрләренең чик саны Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

10. Администрациянең структур бүлекчәләре бурычлары, функцияләре, вәкаләтләре, составы һәм эшчәнлеген оештыру Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана торган нигезләмәләр белән җайга салына.

Администрациянең структур бүлекчәләренә Татарстан Республикасы Рәисе карары нигезендә Администрациянең тиешле структур бүлекчәсе турында нигезләмәдә билгеләнгән аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге белән бәйле бурычлар һәм функцияләр йөкләнергә мөмкин.

11. Администрациянең штат расписаниесе Администрациядәге вазыйфаларны, хезмәткәрләрнең санын һәм вазыйфаи окладларны билгели. Администрациянең штат расписаниесенә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестрында каралган вазыйфалар, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфалар, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе вазыйфасы кертелә.

12. Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенең беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисе идарәсе башлыгы, Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәчесе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары, Татарстан Республикасы Рәисе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисе Департаменты җитәкчесе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты җитәкчесе, Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы вәкаләтле вәкиле, Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы Секретаре, идарә башлыклары, департамент җитәкчеләре Татарстан Республикасы Рәисе указлары нигезендә вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә.

Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчеләре, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе секретариаты җитәкчесе, Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәчесе урынбасары, Татарстан Республикасы Рәисе Департаменты җитәкчесе урынбасары, Татарстан Республикасы Рәисе Департаменты җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисе Департаменты идарәсе башлыгы, Татарстан Республикасы Рәисе Департаменты җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисе Департаменты бүлеге мөдире, Татарстан Республикасы Рәисе Департаменты идарәләре башлыклары, Администрация бүлекләре мөдирләре, Татарстан Республикасы Рәисенең Матбугат хезмәте җитәкчесе, Татарстан Республикасы Рәисе референтлары Татарстан Республикасы Рәисе боерыклары нигезендә вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә.

Администрациянең структур бүлекчәләре җитәкчеләре урынбасарлары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте

вазыйфаларын биләүче башка хезмәткәрләр, шулай ук Администрациянең Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсеннән кала структур бүлекчәләренең Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы булмаган вазыйфаларны биләүче хезмәткәрләре структур бүлекчәләр җитәкчеләре күрсәтүе (тәкъдиме) буенча Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе боерыклары нигезендә вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә.

Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрдән тыш, Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәчесе боерыгы нигезендә вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә.

13. Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе (алга таба – Администрация Җитәкчесе) Администрация эшчәнлеген оештыра һәм аның эшенә турыдан-туры җитәкчелек итә. Администрация Җитәкчесе Администрациягә йөкләнгән бурычларны, функцияләрне һәм вәкаләтләрне үтәү өчен шәхсән җавап бирә.

14. Администрация Җитәкчесе:

федераль дәүләт органнарында, Татарстан Республикасы дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында, шулай ук республика, Россия, чит ил һәм халыкара оешмаларда Администрациянең вәкиле була;

Татарстан Республикасы Рәисенә кул кую өчен бирелә торган указлар, боерыклар, башка документлар проектларына имза сала;

Татарстан Республикасы Рәисе указларын, боерыкларын һәм күрсәтмәләрен үтәүгә контрольне һәм тикшерү эшен оештыра;

Татарстан Республикасы Рәисе йөкләве буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, башка органнар һәм оешмалар утырышларында аның мәнфәгатьләрендә вәкиллек итә;

Татарстан Республикасы Рәисенә Администрация һәм аның структур бүлекчәләре турында нигезләмәләрне, Администрация регламенты проектларын раслауга тәкъдим итә, Администрация хезмәткәрләренең чик саны һәм Администрация хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре турында тәкъдимнәр кертә;

Татарстан Республикасы Рәисенә вазыйфага Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган кандидатуралар буенча тәкъдимнәр кертә;

Администрациядә дәүләт граждан хезмәтенең тиешле вазыйфалары буенча вазыйфаи регламентларны раслый;

Администрациядә дәүләт граждан хезмәте узу белән бәйле мәсьәләләрне хәл итә, Администрация хезмәткәрләрен аттестацияләү, әзерлек узуы, яңадан әзерлек узуы һәм квалификацияләрен күтәрү эшен оештыра, үз вәкаләтләре чикләрендә Администрация хезмәткәрләрен бүләкләү һәм аларга административ җәза бирү буенча чаралар күрә;

Администрациядә хезмәт тәртибен раслый, Администрация бинасына һәм Татарстан Республикасы Рәисе резиденциясенә керү режимын җайга сала;

Татарстан Республикасы Рәисе мәнфәгатьләрендә Россия Федерациясе Югары Судында, Татарстан Республикасы Югары Судында, башка судларда вәкиллек итүгә билгеләнгән тәртиптә ышанычнамә бирә;

Администрация эшчәнлеге мәсьәләләре буенча үз вәкаләтләренә кергән күрсәтмәләр чыгара;

Татарстан Республикасы Рәисе йөкләве буенча башка функцияләрне тормышка ашыра.

15. Администрация Җитәкчесе Администрациядә аларга билгеләп куюны һәм алардан азат итүне Татарстан Республикасы Рәисе башкара торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затларга карата эшкә алучы вәкиле вәкаләтләрен түбәндәгеләргә карата башкара:

хезмәт контрактларын төзү, аларны өзү, гамәлен туктату, аларга өстәмә килешүләр төзү (Татарстан Республикасы Рәисенең вазыйфага билгеләп кую һәм вазыйфадан азат итү турындагы карарлары нигезендә);

вазыйфаи регламентларны раслау;

отпуск бирү һәм хезмәт командировкаларына җибәрү турындагы карарлар кабул итү, түбәндәге вазыйфаларны биләүче затларга карата кабул ителгән карарлардан кала: Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе, Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәчесе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенең беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисе идарәсе башлыгы, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисе Департаменты җитәкчесе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты җитәкчесе, Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы Секретаре, Татарстан Республикасы Рәисенең Матбугат хезмәте җитәкчесе, Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе;

отпуск бирү һәм хезмәт командировкаларына җибәрү турындагы Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе боерыклары рәвешендә хокукый актлар чыгару. Әлеге пунктның дүртенче абзацында күрсәтелгән затларга карата хокукый актлар отпуск бирү һәм хезмәт командировкаларына җибәрү турындагы Татарстан Республикасы Рәисенең тиешле резолюциясе нигезендә чыгарыла.

16. Администрация Җитәкчесе вакытлыча эш урынында булмаган чорда аның вазыйфаларын Администрация Җитәкчесенең беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисе идарәсе башлыгы башкара.

Администрация Җитәкчесенең беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисе идарәсе башлыгы эш урынында булмаган вакытта,

Администрация Җитәкчесе йөкләве буенча, Администрация Җитәкчесе вазыйфаларын аның урынбасарларыннан берсе башкара.

17. Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе үзенә буйсынган структуралар аша Татарстан Республикасы Рәисен матди-техник яктан тәэмин итүне һәм аңа социаль-көнкүреш хезмәт күрсәтүне тормышка ашыра, шулай ук Администрацияне, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы консультатив, киңәшмә һәм башка органнарны һәм алар тарафыннан уздырыла торган чараларны мәгълүмати, финанс, матди-техник яктан тәэмин итә, Администрация хезмәткәрләре өчен социаль-көнкүреш шартларын тәэмин итүне оештыра, үз вәкаләтләре чикләрендә Администрация сметасы нигезендә финанс чаралары белән эш йөртә.

18. Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе үзенә йөкләнгән вәкаләтләрне үтәгәндә юридик зат хокукларына ия була, үз эшчәнлеген тормышка ашыру өчен мөһерләре, штамплары, бланклары була, банкларда һәм башка кредит оешмаларында исәп-хисап счетлары һәм агымдагы счетлар ача.

19. Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы вәкаләтле вәкиле, Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчеләре, референтлары Татарстан Республикасы Рәисенә аның эшчәнлеге мәсьәләләрен хәл итүдә булышлык күрсәтә һәм үз функцияләрен вазыйфаи регламентлар нигезендә тормышка ашыра. Татарстан Республикасы Рәисенең ярдәмчеләре, референтлары саны Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан билгеләнә.

20. Администрациянең структур бүлекчәләре җитәкчеләре үзләренә буйсынган структур бүлекчәләр эшчәнлегенә җитәкчелек итүне әлеге Нигезләмә, Администрациянең тиешле структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр, вазыйфаи регламентлар нигезендә тормышка ашыра.

21. Дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләр үз функцияләрен һәм вәкаләтләрен Администрация Җитәкчесе тарафыннан раслана торган Администрациянең тиешле структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар нигезендә тормышка ашыра.

22. Администрация хезмәткәрләренең хокуклары һәм бурычлары «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, Татарстан Республикасы Рәисе указлары һәм боерыклары, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, шулай ук әлеге Нигезләмә һәм вазыйфаи регламентлар нигезендә билгеләнә.

23. Администрациянең дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләре түбәндәгеләргә бурычлы:

дәүләт граждан хезмәте турындагы гамәлдәге законнарның нигезләмәләрен, әлеге Нигезләмәне, тиешле структур бүлекчәләр турында нигезләмәләр һәм Администрация регламентын үтәргә;

тиешле вазыйфаи регламент нигезендә билгеләнгән функцияләрне һәм вәкаләтләрне, Татарстан Республикасы Рәисе, Администрация Җитәкчесе, Администрациянең тиешле структур бүлекчәләре җитәкчеләре күрсәтмәләрен һәм йөкләмәләрен намус белән, төгәл һәм үз вакытында башкарырга;

Администрациядә урнаштырылган хезмәт тәртибен, документлар әйләнеше кагыйдәләрен үтәргә;

үзенең һөнәри осталык дәрәҗәсен даими күтәрергә, үз эшчәнлеге стилен һәм ысулларын камилләштерергә, хезмәт бурычларын үтәүгә иҗади карарга;

Администрациядә хезмәте тукталганнан соң хезмәт мәгълүматы булган, Администрациядә эшләгәндә алынган хезмәт эшчәнлеген тормышка ашыру белән бәйле барлык документларны һәм материалларны кире кайтарырга.

Администрация хезмәткәренең дәүләт граждан хезмәте турындагы закон таләпләрен, әлеге Нигезләмәне, структур бүлекчәләр турында нигезләмәләрне, Администрация регламентын, вазыйфаи регламентын үтәмәве «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган дисциплинар җәзалар бирелүгә китерә.

24. Администрациянең дәүләт граждан хезмәткәрләре булмаган хезмәткәрләре биләгән вазыйфалары буенча бурычларын әлеге Нигезләмәгә, структур бүлекчә турындагы нигезләмәгә таянып башкара һәм хезмәт турындагы законнар нигезендә җаваплы була.

25. Администрациянең дәүләт граждан хезмәткәрләре булган хезмәткәрләренә билгеләнгән тәртиптә дәүләт граждан хезмәткәре вазыйфасына Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан билгеләп куела һәм вазыйфасыннан азат ителә торган вазыйфаи затлар өчен – Татарстан Республикасы Рәисе кул куйган, вазыйфага Администрация Җитәкчесе тарафыннан билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган вазыйфаи затлар өчен – Администрация Җитәкчесе кул куйган хезмәт таныклыгы бирелә.

Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсенең дәүләт граждан хезмәткәре булмаган хезмәткәрләренә Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәчесе кул куйган билгеләнгән үрнәктәге таныклыклар бирелә.

26. Администрацияне тотуга чыгымнарны финанслау тиешле елга Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законы белән Администрацияне тотуга билгеләнгән чыгымнар күләмендә башкарыла.

27. Администрациянең Татарстан Республикасы дәүләт гербы сурәтләнгән һәм «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе» дигән язулы мөһере, шулай ук үз эшчәнлеген тормышка ашыру өчен кирәкле башка мөһерләре, штамплары һәм бланклары була.

Администрация эшчәнлеген финанс ягыннан һәм матди-техник тәэмин итү юридик зат хокукларына ия булган Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе аша башкарыла.

28. Администрациянең урнашкан урыны: 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Кремль.

___________

Татарстан Республикасы
Президентының
2023 елның « 04 »февралендәге
ПУ- 68 номерлы Указына
3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлеге**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестры турында» 2006 елның 18 гыйнварындагы ПУ-9 номерлы Указында (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 мартындагы ПУ-121 номерлы, 2010 елның 1 апрелендәге ПУ-183 номерлы, 2010 елның 10 июнендәге ПУ-378 номерлы, 2010 елның 30 июнендәге ПУ-416 номерлы, 3 август, 2010 елның 2 сентябрендәге ПУ-585 номерлы, 2011 елның 31 гыйнварындагы ПУ-34 номерлы, 2011 елның 20 июнендәге ПУ-360 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-620 номерлы, 2011 елның 13 октябрендәге ПУ-646 номерлы, 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы, 2012 елның 20 февралендәге ПУ-126 номерлы, 2012 елның 24 маендагы ПУ-375 номерлы, 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы, 2012 елның 20 августындагы ПУ-681 номерлы, 2012 елның 19 октябрендәге ПУ-880 номерлы, 2013 елның 18 гыйнварындагы ПУ-31 номерлы, 2013 елның 18 маендагы ПУ-420 номерлы, 2013 елның 10 августындагы ПУ-754 номерлы, 2013 елның 30 октябрендәге ПУ-1065 номерлы, 2013 елның 23 ноябрендәге ПУ-1143 номерлы, 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1214 номерлы, 2014 елның 22 июлендәге ПУ-708 номерлы, 2014 елның 1 октябрендәге ПУ-949 номерлы, 2015 елның 17 октябрендәге ПУ-995 номерлы, 2016 елның 25 мартындагы ПУ-285 номерлы, 2016 елның 21 октябрендәге ПУ-950 номерлы, 2016 елның 26 ноябрендәге ПУ-1053 номерлы, 2017 елның 12 сентябрендәге ПУ-809 номерлы, 2017 елның 27 октябрендәге ПУ-976 номерлы, 2017 елның 25 декабрендәге ПУ-1156 номерлы, 2018 елның 14 февралендәге ПУ-165 номерлы, 2018 елның 4 августындагы ПУ-549 номерлы, 2019 елның 13 августындагы ПУ-466 номерлы, 2020 елның 15 октябрендәге ПУ-697 номерлы, 2021 елның 1 февралендәге ПУ-73 номерлы, 2021 елның 12 июлендәге ПУ-565 номерлы һәм 2022 елның 17 декабрендәге ПУ-889 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән):

а) 2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты указлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе указлары» сүзләренә алмаштырырга;

б) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестрының 1 кисәген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«1 кисәк.**

**Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә вазыйфалар исемлеге**

## 1 бүлек. «Җитәкчеләр» категориясендәге вазыйфалар

### Иң югары вазыйфалар төркеме

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәчесе | 01-1-1-01 |
| Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенең беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисе идарәсе башлыгы | 01-1-1-02 |
| Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисе Департаменты җитәкчесе | 01-1-1-03 |
| Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты җитәкчесе | 01-1-1-04 |
| Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары | 01-1-1-05 |
| Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы вәкаләтле вәкиле** | 01-1-1-06 |
| Татарстан Республикасы Рәисе идарәсе башлыгы | 01-1-1-07 |
| Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Департамент җитәкчесе | 01-1-1-08 |
| Татарстан Республикасы Рәисе Департаменты директоры*** | 01-1-1-09 |
| Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы Секретаре | 01-1-1-10 |
| Татарстан Республикасы Рәисенең Матбугат хезмәте җитәкчесе | 01-1-1-11 |
| Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе бүлеге мөдире | 01-1-1-12 |
| Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе секретариаты җитәкчесе | 01-1-1-13 |

### Баш вазыйфалар төркеме

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәчесе урынбасары | 01-1-2-14 |

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Рәисе Департаменты җитәкчесе урынбасары | 01-1-2-15 |
| Татарстан Республикасы Рәисе Департаменты җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисе Департаменты бүлеге мөдире | 01-1-2-16 |
| Татарстан Республикасы Рәисе Департаменты җитәкчесе урынбасары | 01-1-2-17 |
| Татарстан Республикасы Рәисе Департаменты җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисе Департаменты бүлеге мөдире | 01-1-2-18 |
| Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе бүлеге мөдире | 01-1-2-19 |
| Татарстан Республикасы Рәисе идарәсе башлыгы урынбасары | 01-1-2-20 |
| Татарстан Республикасы Рәисе Департаменты идарәсе башлыгы урынбасары | 01-1-2-21 |
| Татарстан Республикасы Рәисе Департаменты идарәсе башлыгы урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисе Департаменты идарәсе бүлеге мөдире | 01-1-2-22 |
| Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Департамент җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Департамент бүлеге мөдире | 01-1-2-23 |
| Татарстан Республикасы Рәисе Департаменты директоры урынбасары | 01-1-2-24 |
| Татарстан Республикасы Рәисе идарәсе башлыгы урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисе идарәсе бүлеге мөдире | 01-1-2-25 |
| Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе бүлеге мөдире урынбасары | 01-1-2-26 |
